ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«26» апрель 2022 ел № 57-р

Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2022» массакүләм ярышлары үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 15 августындагы 1996-р номерлы «Татарстан кроссы - 2019» республика массакүләм ярышларын уздыру турында карары нигезендә:

1. Агымдагы елның 6 маенда Әгерҗе муниципаль районында Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Ометов ур., адрес буенча «Тынычлык эстафетасы - 2022» массакүләм ярышларын (алга таба - ярышлар) оештырырга һәм үткәрергә.

2. Расларга:

Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2022» массакүләм ярышларын үткәрү турында нигезләмә (1 нче кушымта);

Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышларын үткәрү турында чыгымнарның сметасын (2 нче кушымта);

Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2022» массакүләм ярыш буенча спорт судьялары коллегиясенең составы (3нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «ОЛИМП» СОК» МБУга:

- чишенү бүлмәсен, «Тынычлык эстафетасы - 2022» массакүләм ярышларында катнашучыларны теркәү өчен урын бирергә;

- Әгерҗе шәһәренең Ометов урамында массакүләм ярышлар үткәрү урынын һәм дистанцияләр билгесен әзерләргә.

4. «Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУга Әгерҗе муниципаль районы мәгариф оешмаларына «Тынычлык эстафетасы - 2022» массакүләм ярышларда катнашу турында хәбәр итәргә.

5. «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУга «Тынычлык эстафетасы - 2022» массакүләм ярышларын медицина персоналы белән тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенә «Тынычлык эстафетасы - 2022» массакүләм ярышлары вакытында җәмәгать тәртибен саклауны тәкъдим итәргә.

7. «Татмедиа» АҖ филиалы - «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы редакциясенә, Әгерҗе районы җирле радиотапшырулар МАУга ярышлар барышы һәм

йомгаклары турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту оештырырга тәкъдим итәргә.

8. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
26.04.2022 № 57-р
күрсәтмәсенә 1 нче кушымта

Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2022» массакүләм ярышларын үткәрү турында нигезләмә

**1.Максатлар һәм бурычлар**

- Әгерҗе муниципаль районында спортны пропагандалау һәм үстерү;
- халыкны физкультура һәм спорт белән массакүләм шөгыльләнүгә җәлеп итү;
- Әгерҗе муниципаль районында иң көчле спортчыларны ачыклау.

**2. Ярышлар уздыру вакыты һәм урыны**

Ярышлар 2022 елның 6 маенда Әгерҗе шәһәренең Ометов урамында үткәрелә.

Ярышлар 11.00 сәгатьтә башлана. 9.30 сәгатьтән командаларны җыю һәм теркәү.

Ярышларның баш хөкемдары - Чечегов С.В.- ТР Әгерҗе муниципаль районының “Спорт мәктәбе” МБУ тренеры.

Баш секретарь - Мөхәммәтҗанова Н.В.-ТР Әгерҗе муниципаль районының “Спорт мәктәбе” МБУ директоры урынбасары.

**3. Ярышларда катнашучылар һәм үткәрү программасы**

Эстафетада катнашуга мәктәпләрнең һәм Әгерҗе муниципаль районы оешмаларының җыелма командалары рөхсәт ителә.
Командалар составы: 5 яшүсмер 5 кыз, командалар саны чикләнмәгән.

**4. Җиңүчеләрне билгеләү тәртибе. Бүләкләү**

1 урынны алган команда һәр йөгерүдә истәлекле Кубок һәм грамота белән бүләкләнә. Команда зачетында 1,2,3 урынны алган эстафетада катнашучылар медальләр белән бүләкләнә.

**5. Финанслау**.

Шәхси беренчелектә бүләкләү буенча чыгымнарны команда зачетында Татарстан Республикасы Әгерҗе районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлеге күтәрә.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
26.04.2022 № 57-р
күрсәтмәсенә 2 нче кушымта

Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышларын үткәрү турында чыгымнарның сметасы

| Товарлар | Саны, штук | Бер штук өчен бәясе | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| Кубоклар | 3 | 1200 | 3600 |
| Грамоталар | 20 | 50 | 1000 |
| Медальләр | 50 | 60 | 3000 |
| Барлыгы | | | 7600 |

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетының
26.04.2022 № 57-р
күрсәтмәсенә 3 нче кушымта

Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2022» массакүләм ярыш буенча спорт судьялары коллегиясенең составы

1. Жуйков Т.В. (Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлеге)
2. Чечегов С.В. ("Спорт мәктәбе" МБУ)
3. Мөхәммәтҗанова Наталия Викторовна («Спорт мәктәбе» МБУ)
4. Тукаева Гөлназ Рәшит кызы («Спорт мәктәбе» МБУ)
5. Добровольская Раушания Илдар кызы («ОЛИМП» СОК» МБУ)
6. Закиров Руслан Рәмзил улы («Спорт мәктәбе» МБУ)
7. Идиятов Илдар Рәмис улы («Олимп» СОК» МБУ)